Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

# КАРАРЫ

11 декабрь 2020 ел №12

Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының «Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 132 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама бистә Советының «Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 132 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2018 елның 05 декабрендәге 139 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районының Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| «Вазыйфаның исеме» | Тугызынчы төркем хезмәт хакы, сум |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 21 387 |
| Бистә башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 20 697 |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме»

| «Вазыйфаның исеме» | Тугызынчы төркем хезмәт өчен түләү буенча авыл җирлекләрендә айлык акчалата түләү күләме, сум |
|---|---|
| Башлык | 21 394 |
| Башлык урынбасары | 17 062 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Түбән Мактама ш.т.б. һәм Тихоновка авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә Башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә Башлыгы Р.А. Бәдретдинов